وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# Дин вә Мәгыйшәт

№2 (145). 13 июль 2012 / 24-шәгъбан-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Фидакарьләребезне беләбезме? ▷2◁



Татарча суфи рухлы әсәрләрнең теле ▷3-4◁



Өстәгә кул хәерлерәк ▷3◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

**МӨФТИ "СӘЛӘТ" ФОРУМЫНДА КАТНАШТЫ**

**8 июль көнне Алексеевск районының Биләр тыюлыгында XVI "Сәләт" Халыкара яшьләр форумы үтте.**

Башка еллардан аермалы буларак, быелгы "Сәләт" фестивале ТР мөселманнары Диния нәзарәте белән бергәлектә оештырылды. Форумда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз, "Сәләт" проектлары җитәкчесе Җәүдәт Сөләйманов, шулай ук татар зыялыларыннан Ренат Харис, Разил Вәлиев, Әнвәр Хәйри һ. б. катнашты.

Район, республика, төбәкара һәм Россия күләмендә уздырылган фән олимпиадаларында һәм конкурсларда, смотрларда, фестивальләрдә, фәнни конференцияләрдә катнашучылар, лауреатлар белән бергәлектә, быел беренче тапкыр 150 алдынгы мөселман яшьләре дә әлеге фестивальдә катнашты.

Чарада Ислам хезмәттәшлеге оешмасының II Яшьләр моделе ачылышы булды, анда дөньяның 45 иленнән вәкил катнашты.

**МАМАДЫШ, ПИТРӘЧ ҺӘМ ЧҮПРӘЛЕ РАЙОНЫ ИМАМНАРЫНА ШӘҺАДӘТНАМӘЛӘР БИРЕЛДЕ**

**Мамадыштан - 31, Питрәчтән - 11, Чүпрәледән 17 дин әһеле имамлык вазифасын раслаучы документка ия булды.**

Илдус хәзрәт, дин әһелләренә шәһадәтнамәләр тапшырганчы, нәзарәт эшчәнлеге турында сөйләде һәм кайбер мәсьәләләргә тукталды. Мәчетләрне газ белән тәэмин итүдә туган кыенлыкларның чишелеш табуы турында хәбәр итте. Нәзарәтнең гомуми бүлек мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин сүзләренә караганда, шәһадәтнамәләр инде республика районнарының яртысына бирелгән. "Шунысы да үзенчәлекле: шәһадәтнамәләр алганнарның 70-80 проценты мәдрәсә тәмамлаган имамнар", - диде ул.

**ЯҢА МӘЧЕТ АЧЫЛДЫ**

**Биектау районының Кече Сулабаш авылында хезмәт куйган дин әһеле, казый, тарихчы Хәсәнгата хәзрәт Габәши (1863-1936) истәлегенә имамның туган ягында мәчет ачылды.**

**КОНФЕРЕНЦИЯ УЗАЧАК**

**ТР Фәннәр академиясе 2012 елның 1 ноябрендә "Бертуган Барудиларның татар мәгърифәтчелегенә керткән өлеше" дип аталган төбәк фәнни-гамәли конференциясен уздыру турында хәбәр итә.**

Җыен күренекле татар педагоглары һәм мәгърифәтчеләре Галимҗан Барудиның тууына - 155, Салихҗан Барудиның тууына 150 ел тулуга багышлана. Конференцияне Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм аның Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге оештыра.

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!**

**Һәр айның 24 нче числосына кадәр почтага барып "Дин вә мәгыйшәт" газетасына язылсагыз, ул сезгә киләсе ай башыннан килә башлаячак.**

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# "Булгария" теплоходы фаҗигасенә бер ел булуга бәйле рәвештә мөфти Илдус хәзрәт Фәизнең МӨРӘҖӘГАТЕ

**"Булгария" теплоходы батуына нәкъ бер ел булды, шулай да әлеге фаҗигане онытырга мөмкин түгел, вакыт узган саен йөрәкләребезне ныграк әрнетә, күңелләребезне һаман да сыкрандыра.**



2011 елның 10 июле - илебез тарихы өчен зур фаҗига көне, якыннарын һәм дусларын югалтканнар өчен иң зур сынау буларак кереп калды. "Булгария" фаҗигасе йөз егермедән артык кешене якты дөньядан алып китте, шул исәптән әле яңа гына яши башлаган сабыйларның гомерләрен өзде. Һәрберебезнең күңелләрен тетрәндереп, сызлануга дучар итте. Адәм баласы - Аллаһы Тәгалә яралткан могҗиза, шуңа да һәр кешенең гомере бәһасез, әлеге фаҗига йөзләгән кешеләрне якты дөньядан алып китеп, күңелләребезне зур югалту ачысы белән тутырды.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән әлеге фаҗигадә якыннарын, туганнарын югалткан гаиләләрнең тирән кайгысын уртаклашам. "Булгария" фаҗигасендә һәлак булган ватандашларыбызны хәтеребездә саклау, рухлары өчен дога кылу, аларның туганнары һәм якыннары өчен сабырлык, күңел тынычлыгы сорау - һәрберебезнең бурычы.

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

# ТАТАР ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕНЕҢ ГАИЛӘ ТОРМЫШЫ

**(XIX йөз - XX йөз башы)**

**Татарлар үзләренең гаилә тормышын элек-электән ислам дине кушуы буенча корырга тырышкан. Халкыбызның мәдәниятен, традицияләрен формалаштыруга асылда нәкъ менә дин хезмәт иткән. Аллаһы Тәгаләгә ышану һәрвакыт берләштерү көченә ия булып, милләтебез язмышына төшкән бик күп авырлыкларны җиңәргә булышкан. Бүгенгә кадәр нәкъ менә шул дин тоту татарларның рус телле халык арасында "эреп" юкка чыкмавына ярдәм итә. Дин җәмгыять яшәешенең иң мөһим нормаларыннан берсе булган әхлакый кыйммәтләрнең югалуыннан саклый. Шунлыктан дин таләпләренә нигезләнеп татарларда гаилә төшенчәсе һәрвакыт бик югары бәяләнеп килде, никахлашу табигый зарурилык булып исәпләнелде.**



*Шәһәр мулласы гаиләсе. XX йөз башы*

Гомер-гомергә татар муллалары гаиләләре халыкның зур игътибар үзәгендә булды. Гадәттә бу гаиләләр зур һәм нык булган. Әйтик, Түнтәр авылының (хәзерге Балтач районында. - **ред**.) танылган имам-мөдәррисе Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов җиде бала тәрбияләп үстерә: Фатыйма, Мөхәммәтрәкыйп, Фарук, Латыйфа, Нурлыгаян, Габделхәй, Нурислам. Тәтеш өязенең Тәүгилде авылы имамы Сәгыйть бине Хәмитнең тугыз баласы була: Сабит, Сәхиб, Гыймран, Гыймадетдин, Мөхәммәтша, Әхмәтша, Җамалетдин, Низаметдин, Гатаулла. Ата-аналар, кагыйдә буларак, улларының гаиләләре белән бергә яшәгәннәр.

Муллалар үзләренең балаларын тәрбияләүгә нык игътибарлы булалар. Алар сабыйларын, мәктәпкә яки мәдрәсәгә биргәнче үк, өйдә бик җентекләп әзерлиләр. Кечкенәдән үк балаларын шәригать кануннарына, укый-язарга, әхлакка һәм хезмәткә өйрәтәләр. Улларын 7-8 яшькә җитүгә башлангыч дин белеме мәктәпләренә укырга җибәрәләр. Шуннан соң алар 20-25 яшькә кадәр мәдрәсәләрдә гыйлем эстиләр, хәллерәкләре чит илләрдә дә дини белемнәрен арттыра. Шул рәвешле белем алгач, күбесе башта мәдрәсәләрдә хәлфә булып эшли, аннан әтиләре урынына яки башка мәхәлләдә муллага әйләнәләр.

Гадәттә, муллалар мәдрәсәне тәмамлаганнан соң гаилә корганнар. Кәләшне егетнең әти-әниләре, башлыча, байлыгына, белеменә, матурлыгына, дәрәҗәсенә карап, күбесенчә башка мулла гаиләләреннән сайлаганнар. Өйләнгәч, мулла үзенә аерым йорт төзегән, мәхәллә халкы аңа бу эшендә зур ярдәм иткән.

Муллаларның кайбер уллары, мәдрәсәне тәмамлагач, сәүдә юлы белән киткән. Мәшһүр этнограф Карл Фукс алар турында болай дип яза: "Муллаларның уллары бервакытта да өйләрендә тормыйлар: алар ел дәвамында ярминкәләрдән кай-

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# ТАТАР ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕНЕҢ ГАИЛӘ ТОРМЫШЫ

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

тып кермиләр, баштарак үзләренең атлары белән олау ташыйлар, аннары шәһәрнең татар сәүдәгәрләренә кибетләрендә эшләргә булышалар. Алар товарлар китерәләр, түкләр бәйлиләр. Шулай итеп, сәүдәгә өйрәнәләр, әкренләп приказчикларга әйләнәләр дә, акча туплаганнан соң, еш кына сәүдәгәр булып китәләр".

Муллаларның кызлары исә, гел әти-әниләре янында булып, төпле башлангыч белем һәм тәрбия алганнар. Ата-ана кызына бирнә хәстәрен күрү белән беррәттән, аның әйбәт хуҗабикә булып үсүен дә кайгырткан. Кыз баланы укый-язарга, ислам дине нигезләренә, шулай ук кул эшенә, милли аш-суга, йортта хуҗалык эшләренә өйрәтәләр. Ә инде 15-16 яше тулуга, башлыча мулла, сәүдәгәр, йә булмаса мещан улына кияүгә бирергә тырышканнар. К.Фукс муллалар турында: "... Аларның кызлары еш кына бай Казан татарларына кияүгә чыга, кызлары өчен кияүдән зур гына калым алалар", - дип яза.

Ул чорда муллалар берсен-берсен яхшы белгәннәр, үзара кунакка йөрешкәннәр, шуңа күрә үз балаларын еш кына таныш муллаларының балалары белән кавыштырганнар. Шулай итеп, үзара мөнәсәбәтләр дуслык-туганлашу белән ныгытылган. Мисал өчен, мәшһүр имам, галим, тарихчы Һади Атласи Түбән Чыршылы (Лениногорск районы) авылының танылган имам-мөдәррисе Габделфәттах хәзрәтнең (аңарда Ризаэддин Фәхреддин 10 еллап чамасы белем ала) кызы Хөсникамалны үзенең гомерлек яры итеп сайлый. Танылган мулла Мөхәммәдзакир ишан Камаловның кызы Әсма дин галиме Муса (Җарулла) Бигиевка кияүгә чыга. Чистай өязенең Яуширмә (Кутлушкино) авылыннан имам Гыйләҗетдин Исхаков (язучы Гаяз Исхакыйның әтисе) Габделвәли мулланың кызы Камәрия белән тормыш кора.

Өйрәнелгән материаллардан күренгәнчә, муллалар гаиләләрендә аерылышулар бик сирәк күренеш булган. Бай муллалар арасында икешәр хатынга өйләнеп яшәүчеләр дә була. Мәсәлән, Мамадыш өязенең Шәдче авылыннан Җамалетдин бине Бикашның, Норлат (Буа районы) авылы имамы Фәхреддин бине Мостайның икешәр хатыны булган. Бу уңайдан танылган дин эшлеклесе, Чистай шәһәре имамы Мөхәммәдзакир ишан Камаловның гаиләсен тасвирлап үтәргә мөмкин. Аның гаиләсе шактый зур була. Ул ике хатынга өйләнеп яши. Бибигасыйма белән беренче никахыннан гына да дүрт бала тәрбияләп үстерә. Кызларыннан берсе - Фатыйма яшьли вафат була, калган икесе - Бибихандәлиф белән Бибихәдичә үзләренең язмышларын имамнар (беренчесе - Мөхәммәдшаһит, икенчесе - Шиһабетдин имам) белән бәйли. Мөхәммәднәҗип дигән улын да затлы нәселдән булган кызга өйләндерәләр. Үзеннән күпкә яшь хатыны Бибифатыймага (аңа 15-16 яшендә кияүгә чыга) Мөхәммәдзакир хәзрәт олы яшьтә өйләнә. Ел саен аларның балалары туып тора. Озакламый балаларының гомуми саны ундүрткә җитә (дүртесе сабый чагында үлә). Аларның күбесе кызлар була. Әминә - имам Нәҗип хәзрәт Шәмсетдиновка (Түнтәри), Камиләттениса - имам Нәҗип хәзрәт Әмирханга, Тарифә - Уразгилдиевка, Әсма-Галия - атаклы дин белгече Муса Бигиевка, Өммегөлсем - фабрикант Абдулла Акчуринга, Шәмсениса - "ярлы" Рөстәм Акчуринга, Җүәйрә - мөгаллим Миргалим Мансуровка кияүгә чыга, Хәтимә исемле бер кызы гражданнар сугышында фельдшер булып хезмәт иткәндә тифтан вафат була.

Танылган дин эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗанинең гаилә тормышы үзенә күрә четерекле була. Ул 1851 елда 32 яшендә Казан ахуны Габденнасыйр бине Рахманколыйның кызы Фатыймага өйләнә. Әмма озакламый хатыны бала тапканда вафат була. 1852 елда Казанда яшәүче Исмәгыйль Апанайның кызы Бибинәгыймә (Нәгыймә) белән икенче гаилә кора. Бу никахтан ун баласы туа (Хәерниса, Борһанетдин, Мәрьям (зурысы), тагын Мәрьям (кечесе), Фәхерниса, Әхмәт, Мәхмүт, Гайшә, Салих, Һава). 19 ел диярлек бергә яшәгәч, 1870 елда бу хатыны да бала тапканда вафат була. Өченче тапкыр Шиһабетдин хәзрәт 1871 елда 53 яшендә Казан сәүдәгәре Хөсәен бине Якубның кызы Бибифатыймага (Фатыйма) өйләнә. Аның бу хатыннан ике баласы (Галия, Нәгыймә) булганлыгы мәгълүм. Соңыннан Буа шәһәренең атаклы имам-мөдәррисе Габденнасыйр ишан Мөхәммәдәминнең (1886 елда вафат) кызы Бибизөһрәне (Зөһрә) икенче хатынлыкка ала.

Шиһабетдин хәзрәтнең Әхмәт, Гайшә, Салих, Мәхмүт исемле балалары һәм ике Мәрьяме дә этиләре исән чакта ук вафат булалар. Ул үтә дә сәләтле булган, бик зур өметләр баглаган 20 яшьлек Мәхмүтенең үлемен аеруча авыр кичерә..

Ә менә мөфти Ризаэддин Фәхреддиннең шәхси тормышы шактый уңай була. Ул 1885 елда 26 яшендә Минзәлә өязенең Чубытлы авылы ахуны кызы Нурҗамалга өйләнә. Бу бәхетле пар 51 ел бергә гомер кичереп, балаларына үрнәк булып, дүрт ул - Габдрахман, Габделәхәт, Габдрәшит, Сәгыйтьне һәм ике кыз - Зәйнәп белән Әсманы тәрбияләп үстерә.

Кыска нәтиҗә буларак шуны әйтик: XIX йөз - XX йөз башларында татар муллаларының гаиләләре шактый ишле, нык һәм тату була. Алар халыкка чын мөселманнарның ничек яшәргә кирәк булуы хакында үзенә күрә бер күрсәткеч, үрнәк булып тора.

***Рәшид хәзрәт МАЛИКОВ,***
***тарих фәннәре кандидаты,***

# ЧИСТАЙ УКУЛАРЫ УЗДЫ



**8 июль көнне республикабызның Чистай шәһәрендә Диния нәзарәте тарафыннан игълан ителгән Коръән елы кысаларында Чистай укулары узды. Әлеге чара Мөхәммәдзакир ишан Камалов гомер буе хезмәт кылган Нур мәчетендә үткәрелде.**

Чарада район башлыгы Илдус Әхмәтҗанов, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз, Татарстанның көньяк төбәге казые Алмаз хәзрәт Шәрифуллин, иганәче Тәлгать Әхмәтҗанов, ТР Дәүләт Советы депутаты Фарит Мифтахов катнашты.

Укуларда филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов "Камалов һәм аның даирәсе", тарих фәннәре докторы Наил Таиров "Мөхәммәдзакир Камалов һәм татар сәүдәгәрләре", Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Илдус Әмирханов "Әмирхановлар белән Камаловларның дин өлкәсендәге эшчәнлеге", тарих фәннәре кандидаты Вәлиулла хәзрәт Якупов "Мөхәммәдзакир хәзрәт Камалов - халкыбызның олуг рухи остазларыннан...", Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәнең ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин "Камалов һәм милләт" исемле тема буенча докладлар ясады. ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы әгъзасы Рәфыйк хәзрәт Насыйров Чистай төбәгендәге татар тарихы белән бәйле изге урыннар турында сөйләде. Барлык галимнәр дә Чистай шәһәре турында чыккан китапларда татар факторына игътибар аз бирелүен ачынып сөйләделәр.

Шулай ук Чистай укулары кысаларында Мөхәммәдзакир Чистави хәзрәтләре Камаловның каберен зиярәт кылу оештырылды. Зиратның үзендә дә күп төзекләндерү эшләре алып барылган - керү ягында тәһарәт алу өчен махсус бина төзелгән. Ишан Мөхәммәдзакир хәзрәтләре дәфен ителгән кабер дә тәртипкә китерелгән, зират янына урындыклар куелган.

# ФИДАКАРЬЛӘРЕБЕЗНЕ БЕЛӘБЕЗМЕ?

**Мохтаҗ кешеләргә, ярлыларга, ятим-толларга һәм авыру-зәгыйфьләргә хәйриялек юлы белән рухи һәм матди ярдәм күрсәтү гамәле бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. Кешелек җәмгыяте цивилизацияле тәрәккыят, үсү юлына баскач, бигрәк тә китаби диннәр оешып киң таралгач, хәйриячелек идеясе дә билгеле бер әхлакый норма, дини тәгълимат күренешенә әверелгән. Кайсы гына диннең өйрәтүләренә мөрәҗәгать итсәк тә, ярдәмчелекнең, ягъни химая-хәйрия эшенең изгелек, иманлылык галәмәте, хәтта хәлле кешеләр тарафыннан эшләнүе зарури бурыч сыйфатында тәкъдим ителүен күрербез.**

Казан ханлыгы яулап алынгач, мәчет-мәдрәсәләр җимерелеп, татар вакыфлары туздырылгач, социаль тормышта шәригать кануннары Россия дәүләте законнары белән алмашынгач, ниһаять, ике-өч гасыр дәвамында татарның милекле өлеше, ягъни аксөяк катламнары, җир биләүчеләре кырыпсебереп дигәндәй юк ителә. Мондый шартларда, вак-төяк сәдака бирүчеләрне исәпкә алмаганда, дәвамлы һәм күләмле хәйрия эшләре белән шөгыльләнү турында уйларга да урын һәм мөмкинлек калмый. Бары XVIII гасырның икенче яртысыннан алып, дөресрәге Әби патша чорында, Россиядә элекке кыргыйлыктан китәргә омтылып, европача цивилизацияле идарә итү алымнары күренә башлагач, татарларга дин тотуда, икътисади тормышта да беркадәр ирек бирелгәч, хәйриячелекнең кайбер күренешләре барлыкка килә башлый. Әйтик, байлардан җыелган иганә исәбенә яңа мәчетләр салыну, алар янында ачыктан-ачык эшли торган мәдрәсәләр тәрбия ителү фактлары. Бу күренеш, әлбәттә, иң элек сәүдәгәрләр катламы оешып, халыкның бер өлешендә хосусый милек-капитал барлыкка килүнең, шуннан хәйриялек максатына өлеш чыгарылуның нәтиҗәсе.

Татар сәүдәгәрләрендә милли капиталның барлыкка килүе, үсүе иң элек руслар үтеп керә алмый торган Шәрыктагы мөселман төбәкләренә юл ачылу белән бәйле. Шәрык илләре белән сәүдә эшләрен җайга салу өчен татарлардан

**(Ахыры 4 нче биттә.)**



# Татарча суфи рухлы әсәрләрнең теле

**Татар халкы тарихында, мәдәниятендә, тел-әдәбият үсешендә мөһим роль уйнаган суфичылык - әт-тасаувыф - катлаулы күренешләрнең берсе санала. Ул әлегә кадәр фәндә система буларак төгәл билгеләмә алмаган күренешләрнең берсе булып тора, суфилар, дин галимнәре, фәлсәфәчеләр, галимнәр тарафыннан төрле эчтәлекләрдә шәрехләнә. Суфилар аны "сыйфат буларак Хакныкы, сурәт буларак халыкныкы булу" (Г.Багдади), "Хакның әхлагы белән бизәнү" (Мөхйетдин ибне әл-Гарәби) кебек шәхси төсмерләрдә аңлата.**

Моннан тыш, суфичылыкның ислам дине тарихында берничә төрле һәм каршылыклы эчтәлекләрдә билгеләнүе дә очрый. Мәсәлән, төрек галиме Осман Нури Топбаш аның алты мәгънә калыбында шәрехләнүен билгели: суфичылык - камил һәм гүзәл әхлак (Әбул Хөсәен ән-Нури, Әбу Мөхәммәд Җәрри, Әбу Бәкер әл-Каттани); суфичылык - күңел, калебне чистарту; суфичылык - эчке күңел көрәше; суфичылык - эчкерсезлек; суфичылык - Аллаһка юл; суфичылык - буйсыну һәм шуннан канәгатьлек алу. Билгеләмәләрдән күренгәнчә, суфилар тарафыннан ул әхлакны чистарту аша Аллаһка омтылу юлы, рухи халәтләрне өйрәнә торган фән буларак тәкъдим ителә. Галимнәр тарафыннан да ул төрлечә аңлатыла. Карл В. Эрнст суфичылыкның фәнни әйләнешкә әдәби каналлар аша керүен күрсәтә. Аның фикеренчә, XVIII йөздә Көнчыгышны өйрәнүче инглиз галимнәре суфичылык күренешен ислам диненнән аерым агым, Көнчыгыш мәдәниятенең бер кисәге буларак аңлата башлый. XX гасырда суфичылык атамасы, Көнчыгыш дөньясында гына түгел, инглиз, немец, рус, татар галимнәре хезмәтләрендә дә фәнни өйрәнү үзәгенә куела, ислам дине кысаларындагы бер агым, иҗтимагый күренеш һәм аң формасы төсендә кабул ителә башлый. Мәсәлән, суфичылыкны өйрәнүче галимнәрдән А.Д. Кныш, А.Шиммель хезмәтләрендә ул мистик агым буларак билгеләнә. Дж. Тримингем тарафыннан "ислам дине кысаларында дөньяга мистик, дини-фәлсәфи караш формасы" дип аңлатыла. Фәлсәфи планда суфичылык тәгълиматы Аллаһның үзе тудырган барлык нәрсә белән монистик эреп бетүе турындагы өйрәтмә кебек аңлатыла. Я.Абдуллин аны "ислам дөньясында зур яңгыраш тапкан, зөһедлекне, дөньявилык белән мавыкмауны, сабырлыкны, күңелне изгелеккә баглауны, тормыш сынауларын түземлелек белән үткәрүне алга сөргән агым" төсендә шәрехли. Суфичылык тарихын, аның үсешүзгәрешен монографик өйрәнгән галимә Ә.Сибгатуллина хезмәтләрендә ул "ислам мистицизмы һәм зөһедлеккә нигезләнгән дини-мистик һәм фәлсәфи юнәлеш, мөселман-суфиның Аллаһка карата булган гыйшкын, аның белән кавышу идеясен алга сөргән ислам динендәге мистик-аскетик агым" дип билгеләнә. Гомумиләштереп әйткәндә, фән суфичылыкны ислам динендәге бер мистик агым, фәлсәфи юнәлеш буларак алга куя.



Суфичылык игътибар үзәгенә кеше һәм аның күңелен, калебен ала, кешенең рухи камилләшү, үзара дуслык, Аллаһ каршында тигез булу проблемаларын яктырту чыганаклары булып Коръән һәм Сөннәт санала. Бу юлга баскан кеше Аллаһны тануны, яратуны, хакыйкатькә ирешүне алга куя, дөньяны хис аша таный, шуңа бәйле төстә ул "илаһи гашыйк дөньясы" төсендә дә шәрехләнә. Суфилыкка ирешү юлында берничә баскыч - мәкам эшләнә. Беренче дәрәҗә булып тарикать санала, бу баскычта кануннар белән танышу алга сөрелә, күбрәк тышкы якка басым ясала. Икенче баскычны һидаять баскычы тәшкил итә, ул туры юлга керүне, хакыйкатьне эзләү теләгенә килүне аңлата. Өченче - мәгърифәт баскычында суфи "тасаувыф шигырьләр уку белән шөгыльләнә, алар белән илһамлана, үзен хакыйкатьне аңларга әзерли... илаһият белән берләшергә омтыла. Дүртенче баскычта, ягъни хакыйкать дәрәҗәсендә, дәрвиш суфилыкның иң югары ноктасына ирешкән була, суфи үзен Аллаһның бер кисәге дип хисаплый".

Суфиларга хадарат - даими бергә җыелу һәм төп максаты күңелне Аллаһ хозурына тапшыру булган зекерне әйтү, шуның аша, транс, экстаз дәрәҗәсенә җитеп, Аллаһны күрергә, аның белән кушылырга омтылу хас. Суфилар барытик Аллаһ яшәешен генә таныйлар, әйләнә-тирәдәге әйберләр, күренешләр, алар фикеренчә, - Аллаһның эманациясе генә. Шуңа да кешенең төп максаты - бу дөньядан ваз кичеп, җанның Аллаһ белән кавышуына ирешү. Әлеге тәгълимат вәкилләре Абсолют хакыйкать белән кушылу экстаз вакытында гына булырга мөмкин дип саный.

Суфичылык галимнәре бу агымның башлангыч чорына материалистик элементлар белән кушылган пантеизм хас булуын билгели. Соңрак неоплатонизм, һинд фәлсәфәсе тәэсирендә тасаувыфта үзәк урынны зөһедлек һәм мистиклык ала.

Суфичылык тәгълиматының мөһим бер ягын танып-белү проблемасы тәшкил итә. Суфичылык концепциясенә караганда, гностиканың (арифның) төп бурычы югары максатка - хакыйкатьне танып белүгә ирешүдән гыйбарәт. Әлеге максатка үз-үзеңне камилләштерү һәм танып белү юлы белән ирешелә. Шуңа мөнәсәбәттә ислам суфичылыгының фундаменталь идеясе - үз-үзеңне яки гүзәл дөнья феноменнарын танып белү аша Илаһине танып белү идеясе. Танып белүгә мөнәсәбәттә суфичылыкта мистицизм концепциясе чагылыш таба. Галимнәр тарафыннан мистицизм "танып белүнең иң югары ноктасы итеп яшәешнең серле, яшерен асылына интуитив, турыдан-туры төшенүне күрсәтә торган дини-теологик концепция" буларак билгеләнә.

Үз асылын танып белү процессында кеше үзендә нindидер илаһи нәрсә барлыгын, Аллаһны танып белүнең бердәнбер дөрес чарасы кешенең үз-үзен өйрәнүе икәненә төшенә башлый. Бу - хакыйкатьне танып белүнең төп юлы санала. Әмма танып белүнең мондый баскычына күтәрелер өчен юлчыга үзенең бөтен барлыгын үз "мин"ен танып белүгә багышлау зарур. Аңа суфиларча яшәү рәвешен сайларга, мистик танып белүнең төп баскычларын: шәригать, тарикать, хакыйкать һәм төп тукталышларны (мәкамнәрне) үтәргә, хакыйкатькә бару юлында юлчы алдына куела торган башка төр таләпләрне башкарып чыгарга кирәк була. Суфилар фикеренчә, белем - үз-үзеңне, ягъни илаһи "мин"не белүгә, Абсолют хакыйкатькә илтә.

Суфичылыкта аскетлык, дәрвишлек көчле. Урта гасыр гарәп-мөселман фәлсәфи фикеренең иң киң таралыш алган юнәлешләреннән берсе саналган суфичылыкның халык арасында киң таралуының бер сәбәбен дә галимнәр шушы сыйфат белән бәйләп аңлата. Аскетизмның нигез принципларының берсен хәлвә тәшкил итә. А.Кныш фикеренчә, "суфичыл өйрәтүдә "ялгызлык, читләшү" мәгънәсендәге хәлвә термины (хәлә - ялгызлыкта калу фигыленнән) мөһим урын тота", кешесез, тыныч урында ялгыз калу яки тау куышында, бикле бүлмәдә утыру гадәттә Аллаһ һәм тормыш хакында киеренке уйланулар, чикләүләрне һ. б. таләп итә. Суфилар шушы юл белән Аллаһка омтыла, кушыла ала дип санала.

Исламдагы бу юнәлеш VIII-IX гасырларда барлыкка килә һәм Гарәп әмирлекләрендә таралыш ала. Мөхәммәд (сгв) үлгәннән соң, Әбу Бәкер һәм Гомәр хәлифәләр вакытында, аеруча өченче хәлифә Госман вафатыннан соң мөселман дөньясында таркаулык арта. Шушы шартларда хәдисләрне җыю эше көчәеп, бу вазифаны башкаручылар - мөхәддисләр барлыкка килә. Нәкъ менә алар VII гасыр ахырларында мөселман аскетлыгын нигез итеп алган хәрәкәтне нигезли. Бу вакытта суфи сүзе кулланылышта булмыйча, "заһид", ягъни Аллаһка хезмәт итүче дигән төшенчә еш очрый.

Татар халкы арасында да суфичылык тәгълиматы киң җәелгән булган. Бу төбәктә аның чагыштырмача тиз таралуы мөселман дәүләтләре белән тыгыз икътисади, рухи бәйләнешләрдә булу белән дә, тарихи-географик шартларга мөнәсәбәтле дә аңлатыла ала. Галимнәр X-XII гасырларда яшәгән Болгар дәүләте чорыннан алып, 1917 елгы инкыйлабка кадәр татар халкы тормышында суфичылыкның, төрле үзгәрешләр кичереп, төрле шәкелләргә кереп, ислам дине белән бергәлектә яшәвен күрсәтә. Идел буе Болгар дәүләте тарихына караган тарихи истәлекләрдә Гарәбстан, Иран, Урта Азия якларыннан килеп, әлеге гыйлемне тараткан күренекле суфи галимнәр белән бергә, Болгарның үз суфилары булуы турында да хәбәрләр килеп җиткән.

Суфичылык хәрәкәте Алтын Урда чорында да актив булып, халыкны берләштерү, ислам диненә тарту вазифасын башкара. XVII гасырда ул халыкка рухи терәк, үз-

(Ахыры 4 нче биттә.)

# Өстәге кул хәерлерәк

**Мәдрәсәдә дәрес бара. Венера абыстай Яруллина зәкят турында сөйли. Төркемдәшебез Рузалия Ибраһимова сорау арты сорау яудыра. Күптән аңладык инде: алган гыйлемнәре белән тиз арада гамәл кыла башлаучылардан ул. Башкаларны да шуңа өйрәтә. Гомер буе шулай.**

Кукмара районының Тырыш авылында биш кызлы гаиләдә дөньяга килә Рузалия. Әтисенең: "Йорт сала башласаң шифер, пыяла юк. Нәрсәгә тотынсаң, шул юк. Төп нигездә калдырырга малай да юк!" - дигән сүзләрен үзенә атап әйткәндәй кабул итә. Һәм мәктәпне тәмамлауга Казан кооперация техникумына юл тота. Исәбе - тизрәк товаровед булып, әтисенә йорт салырга булышу, кешечә яши башлау. Яшь кызны Янил сельпосына товаровед итеп билгелиләр. Эшлеклелеген күреп, Ядегәр авылына дүрт сатучылы кибеткә мөдир итеп җибәрәләр. Шунда үзенең тиң ярын - Илгизәр исемле агроном егетне таба. Өйләнешәләр. Бала туа. Эшкә чыгасы килә, баланы куярга урын юк. Шундый зур авылда ясле дә юк. Иске контораны ремонтлап, китаплардан укый-укый, 25 сабыйга исәпләнгән балалар бакчасы ачалар. Рузалия Нәкыйповна анда тугыз ел буе мөдир була. Әнә шулай тормыш сабаклары ала-ала, көн күрергә, җитәкче булырга өйрәнә ул. Шул елларда бер-бер артлы алып кайткан өч баласы да бирелдә үсә. Язмыш җилләре әлеге гаиләне Мамадышка китерә. Яшүсмер балаларына игътибар бирү ниятеннән чыгып, икътисадчы булып эшли башлый. Балалар үсеп җитә. Лилия, Алсу, Илшат -өчесе дә мәктәпне алтын медальгә тәмамлыйлар. Табиб, икътисадчы һөнәрләрен сайлыйлар. Инде барысы да башлы-күзле булдылар. Илдә үзгәреш җилләре исә башлагач, иң беренчеләрдән булып, эшмәкәрлеккә кыю атлады Рузалия Нәкыйповна. Бүген күпләргә үрнәк итеп куярлык "Пирамида" ҖЧҖен җитәкли. Оешманың игелекле эшләре турында әледән-әле ишетеп торабыз. Мохтаҗлар аның иганәчелек ярдәмен һәрдаим тоеп яшиләр. Нәсел-нәсәбне учка туплап тотучы да ул. "Татнефтепродукт" ААҖенең Мамадыш филиалы директоры Илгизәр Рәфкатович белән мондый тату, матур парны бер-берсеннән башка күзаллау мөмкин түгел. Гаилә кошы ике канатын да тигез җилпеп очканда тагын да ныграк, матуррак, ышанычлырак шул. Алар соңгы елларда чит илләргә сәяхәт итәргә яраталар. Дөньядагы бар матурлыкны Мамадышка алып кайтмакчылар. Энгельс урамындагы мәһабәт йортлары, филиалның административ бинасы, ягулык салу станцияләре яннары искиткеч зәвыклылыгы белән аерылып тора.



Эшмәкәр Рузалия Ибраһимова Мамадыш мәдрәсәсенең беренче шәкертләреннән булды. Тормышын Коръән нигезендә корырга, күңел тынычлыгы, рух һәм иман ныклыгы белән яшәргә, тәкъвалыкка омтылырга тырыша ул. Берничә тапкыр хаҗ гамәле кылды. Олы җанлы, миһербанлы, намуслы, гаделлек сөюче, ярдәм кулы сузарга әзер торучы, үзенә теләгәнне башкаларга да теләүче чын кеше булганы өчен без аны яратабыз, хөрмәт итәбез. Бүген тормыш аңа ике "биш"ле куйды. Лаеклы ялга чыгарга вакыт. Тик өйдә утыру аның өчен түгел: ул Мамадышта "Димче" клубы оештыру хыялы белән яна. Яучылык серләренә төшенә. "Дөньяда бар кешеләр парлы, бәхетле, иманлы булсыннар!" - дип тели. Кылган игелекләре үзенә меңе белән әйләнеп кайтсын, ике дөнья бәхете насыйп булсын.

*Алсу ДИЯР,*
*Мамадыш районы*

# Татарча суфи рухлы әсәрләрнен теле

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

үзен, милли сыйфатларын саклап калу хезмәтен үти.

XVIII-XIX гасыр чикләрендә суфичылык үзенчәлекле үсеш-үзгәреш юлына керә, әлеге процесска карата фәндә фикер төрлелеге хөкем сөрә. XVIII гасырда татар дөньясында суфичылык дини реформаторлык хәрәкәтенә көчле йогынты ясый. Шушы чордагы иҗтимагый-сәяси барышка мөнәсәбәтле суфичылык хәрәкәтенең активлашуы турында галимә Р.Харрасова болай дип яза: "Алгарышны алга сөргән мәгърифәтчелек идеологиясе көчәйгән бер чорда традициональлекне яклаучылар, шуның бер формасы саналган суфичылык та активлаша. Бу ил эчендәге эчке көрәшләр һәм дөньякүләм вакыйгалар белән бәйле".


Дж.С.Тримингэм XIX гасырда бар мөселман дөньясында суфичылык тәҗрибәләренең йомшаруы нәтиҗәсендә суфичылык орденнарының яңарышы күзәтелүен ачыклый. Профессор А.Юзеев агымдагы чорда аның сизелерлек дәрәҗәдә йомшаруын, арткы планга күчүен күрсәтә. Ләкин филология фәннәре докторы Р.Ганиева милли җирлектә аның йомшармавын, ә бәлки башка юнәлештә - иҗтимагый яктан тирәнәюен, үсү-үзгәрүен күрсәтә. Чыннан да, XIX гасыр иҗтимагый тормышында, әдәбиятында суфичылыкның әле көчле булуы күзәтелә.

Төрки халыклар яшәгән җирләрдә (Урта Азия, Төркестан, Азәрбайҗан, Идел-Урал буйлары) таралган суфичылык хәрәкәтен "төрки суфичылык" термины белән атау кулланылышта йөри. Идел буе Болгар дәүләтенә суфичылыкны Урта Азия сәүдәгәрләре алып килә, биредә суфичылыкка халык үз гореф-гадәтләрен дә беркетә, куша.

Төрки суфичылыкта, гарәп суфичылыгыннан аермалы буларак, рәсми исламга каршы чыгу күзәтелми, ислам белән суфичылык бер-берсенә керешеп китә; ишан һәм указлы мулланы бер кешедә күрү мөмкинлеге яши, ишан бер үк вакытта рәсми дин әһеле дә булып тора; рухи җитәкче, рухи остаз мәгънәсендәге ишанчылык күренеше табигый санала.

Билгеле булганча, суфичылык әдәбиятының башлангыч чорында гарәп теле нигез телләрнең берсе булып санала. Соңрак - XI гасырдан башлап - әдәби әсәр һәм фәлсәфи трактатлар фарсы телендә дөнья күрә башлый, фарсы телле суфичылык поэзиясе Иран, Әфганстан, Урта Азия, Азәрбайҗан, Төркия, Һиндстан төбәкләрендә үсеш ала. Инглиз белгече Аннемари Шиммель билгеләп үткәнчә, "суфичылык тел үсешенә дә зур йогынты ясый: юристлар, дин белгечләре һәм тәрҗемәчеләр суфичылыкка хас әйләнмәләрне тел өлкәсенә алып кереп, гарәп телен баета һәм камилләштерә, аны сыгылмалы итә, мәгънә җиткерү мөмкинлекләрен киңәйтә". Поль Нвийа мистикларның "аутентик" тел барлыкка китерүен ачыклый һәм нәкъ менә мистиклар ярдәме белән гарәп телендә күп мәгънәле, яшерен эчтәлекле сүзләрнең артуын билгели. Аның фикеренчә, суфичылык текстларында тел-сурәтләү чаралары гади, бизәк чарасы булудан туктап, мәгънә тирәнлеген, мистик эчтәлекне җиткерү баскычына күтәрелә. Суфилар тарафыннан бик күп символ, метафораларның файдалануы нәтиҗәсендә тел стилистик җәһәттән байый, тулылана, А.Шиммель аны "стилистик яктан катлауландырылган техник тел" буларак билгели. Н.Пригарина фикеренчә, мондый стилистик катлаулылык XI-XII гасыр чикләрендә канун дәрәҗәсенә күтәрелә һәм гадилек инде түбән стиль буларак кына кабул ителә башлый. Бу фикер татар теле мисалында да раслана, татар суфичылык поэзиясе телендә дә тел-сурәтләү чаралары, образлылыкның гына түгел, грамматик формаларның да стилистик вариантлар тәшкил итүе күзәтелә.

***Айрат ЮСУПОВ,***
***филология фәннәре кандидаты***

**ООО «Ритуальные услуги»**
**Изготовление памятников и оград**

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница -
с 9:00 до 18:00,
суббота - с 9:00 до 13:00.
**Тел.: 225-28-90, 293-25-61**

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00,
вторник - выходной.
**Тел.: 8-927-427-16-02, 293-45-93**

**На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата.**
**Тел. 297-28-90**

Реклама


# ФИДАКАРЬЛӘРЕБЕЗНЕ БЕЛӘБЕЗМЕ?

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

файдалану мөмкинлеге идеясен XVIII йөзнең урталарында патша хөкүмәте дә танырга мәҗбүр була.

Әгәр егерме-утыз ел эчендә генә Россиядәге татарлар яшәгән төрле җирләрдә йөзләгән-йөзләгән яңа типтагы яки яңартылган мәктәп-мәдрәсәләр барлыкка килүен җентекләп тикшерсәк, алар арасында "Мөхәммәдия", "Хөсәения", "Мәрҗания", "Госмания", "Галия", "Касыймия", "Әмирхания", "Рәсүлия", "Мотыйгыя" кебек шәһәр уку йортларын, шулай ук Иж-Бубый, Кышкар, Каргалы, Эстәрлебаш, Бәрәскә шикелле бер-берсенә охшамаган дистәләгән-дистәләгән авыл мәктәп-мәдрәсәләренең тарихларын өйрәнә башласак, без күпләгән химаячеләр, хәйриячеләр белән очрашыр идек.

Әгәр "Тәрҗеман" газетасының ничек, кемнәрнең идеясе һәм матди ярдәмнәре белән чыгу, озак яшәү фактларын барлап, 1918 елга кадәр чыккан башка дистәләгән татарча газета-журналларыбыз язмышларында да актарынсак, тагын милли хәйриячеләребезнең исемнәрен телгә алыр идек.

Игътибар итик: боларның барысы дүрт йөз елга якын дәүләткә барлык салымнарны түләп килгән, солдатка газиз балаларын биргән (башта һәммә җир милекләре дә "казнага күчкән"), ләкин үзенең рухи, мәдәни ихтыяҗлары өчен шул дәүләттән бер тиен дә алмаган, ала алмаган татарларның үз омтылышлары, үз аң-белемнәре, үз тырышлыклары, үз матди көчләре белән барлыкка китерелгән казанышлары - милли хәзинәсе иде.

Нәкъ шушы урында укучыларның бер сорау куюы ихтимал: кемнәр соң ул йөзләгән мәктәп-мәдрәсәләрне тәрбияләп, әлеге чагыштырмача аз тиражлы газета-журналлар чыгаруга матди җирлек тудырган фидакарь затлар?

Дөресен әйткәндә, бу сорауга без хәзергә барлык төгәллекләре белән, эшчәнлекнең төрле якларын чагылдырган хәлдә, тулы җавап бирә алмыйбыз. Нибары шул юнәлешләрдә актив һәм эзлекле рәвештә эшләгән бер уч фамилияне генә атый алырбыз. Образлы итеп әйткәндә, хәзергәчә үзебез анык белгән олы затларның фамилияләрен санап чыгар өчен дә бер кешедәге кул-аяк бармаклары артыгы белән җитәр иде. Мәсәлән: Алкиннар, Апанаевлар, Акчуриннар, Баязитовлар, Борнаевлар, Галиевләр, Дибирдиевләр, Кәримовлар, Насыйровлар, Нигъмәтуллиннар, Рәмиевләр, Сәйдәшевләр, Хөсәеновлар, Юнысовлар, Яушевлар...

Тагын күпме исем өстәп булыр боларга? Ә инде һәр авыл саен диярлек үз чыгымнары белән мәчет-мәдрәсәләр салдырган, дәвамлы рәвештә аларны тәрбияләгән яки мәхәллә иницативасы белән җәмәгатьчелектән хәл кадәри һәм чамалы гына акча җыелган шундый эшләргә үзләреннән зур өлеш керткән "урта кул" хәйриячеләребезнең исемнәрен йөздән унын гына булса да санап чыга алабызмы? Юк, әлбәттә. Бигрәк тә аерым-аерым рәвештә фикер йөртеп, бер-ике кешенең "хәтер янчыгында" гына калган чакта...

***Нияз САБИРҖАНОВ***

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 14.07.12 | 2:48 | 4:18 | 13:02 | 18:34 | 21:20 | 22:50 |
| *Якшәмбе* | 15.07.12 | 2:50 | 4:20 | 13:02 | 18:33 | 21:18 | 22:48 |
| *Дүшәмбе* | 16.07.12 | 2:51 | 4:21 | 13:02 | 18:32 | 21:17 | 22:47 |
| *Сишәмбе* | 17.07.12 | 2:53 | 4:23 | 13:02 | 18:31 | 21:16 | 22:46 |
| *Чәршәмбе* | 18.07.12 | 2:54 | 4:24 | 13:02 | 18:30 | 21:14 | 22:44 |
| *Пәнҗешәмбе* | 19.07.12 | 2:56 | 4:26 | 13:02 | 18:29 | 21:13 | 22:43 |
| *Җомга* | 20.07.12 | 2:58 | 4:28 | 13:02 | 18:28 | 21:11 | 22:41 |
| *Шимбә* | 21.07.12 | 2:59 | 4:29 | 13:02 | 18:27 | 21:09 | 22:39 |

**ИГЪТИБАР!** ***20 июльдән Изге Рамазан ае башлана. Беренче тәравих намазы 19 июль көнне ястү намазыннан (22 сәгать 43 минут) соң укыла. Сәхәр исә кояш чыгарга ике сәгать кала тәмамлана. Әйтик, 20 июль көнне сәхәрне ике тулып егерме сигез минутка (2.28) ашап бетерү тиешле. Авыч ачу - кояш баеганнан соң (ахшам намазы вакыты - 21.11). Бу - Казан шәһәре буенча шулай. Татарстан район-шәһәрләре өчен кояш чыгу һәм кояш бату вакытларын Интернеттан карагыз!***







**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 2 (145) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма − Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9407.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 12 июль көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы − "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**